# КАРАР

**2022 ел, 28 март** **№ 1**

**«Кукмара муниципаль районының Чигайка авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 16 ноябрьдәге 1 нче номерлы карарга үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районының Починок-Кучук авыл җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 28 матында түбәндәге мәсьәлә буенча уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районының Починок-Кучук авыл җирлеге Чигайка авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Чигайка авылы уздырылган гражданнар җыенының 2021 елның 16 ноябрьдәге 1 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә Сез ризамы?:

- 2 пунктта «1000 сум» сүзләрен «2500 сум» сүзләренә алмаштырырга;

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 20 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 13.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен гражданнар җыенының 10 катнашучысы тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен гражданнар җыенының 3 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Починок-Кучук авыл җирлеге Чигайка авылы гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Кукмара муниципаль районының Починок-Кучук авыл җирлеге Чигайка авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Синерь поселогында уздырылган гражданнар җыенының 2021 елның 16 ноябрьдәге 1 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә Сез ризамы?»

- 2 пунктта «1000 сум» сүзләрен «2500 сум» сүзләренә алмаштырырга;

«РИЗА» «КАРШЫ».

кабул ителгәнгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Кукмара муниципаль районы рәсми сайтында игълан итәргә һәм www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Починок-Кучук
авыл җирлеге башлыгы Р.А. Гыйниятов